| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>НУРЛАТСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ<br>РАЙОН<br>ГЛАВА АМЗИНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br>ӘМЗӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>БАШЛЫГЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** Яңа Әмзә ав. **КАРАР**

«14» октябрь 2024 ел № 5

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Әмзә авыл җирлеге Кызыл Юл поселогында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Әмзә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 23 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Әмзә авыл җирлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ:

1. 2024 елның 23 октябрендә 10 сәгать 00 минутта Кызыл Юл поселогы, Гагарин урамы, 15нче йорт адресы буенча урнашкан Биләр урманчылыгы конторасы бинасы янында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Әмзә авыл җирлеге Кызыл Юл поселогында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын уздыруны билгеләргә.

2. Гражданнар җыены этапларын үткәрү һәм оештыру эшләре Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Әмзә авыл җирлеге башлыгы һәм башкарма комитеты тарафыннан тәэмин ителә.

3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Әмзә авыл җирлеге Кызыл Юл поселогында яшәүче, 1 гр инвалидтан тыш, балачактан инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол калган хатыннарыннан, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан тыш, балигъ булган һәр кешедән 2025 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

1) янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (Кызыл Юл торак пунктында янгынга каршы гидрант сатып алу һәм урнаштыру);
2) Кызыл Юл торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;
3) Кызыл Юл торак пункты чикләрендә тышкы яктырту урам челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләре һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җайланмаларны ремонтлау.

«РИЗА» «КАРШЫ»

4. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru., Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru/, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Кызыл Юл поселогы мәгълүмат стендларында гражданнар җыены этапларын үткәрү датасына 10 көннән дә соңга калмыйча бастырып чыгарырга (игълан итәргә).

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Әмзә авыл җирлеге башлыгы Ә.Ф.Сафиуллина